УДК 371

# РОССИЯ МӘГАРИФЕНДӘ ТУГАН ТЕЛЛӘРНЕҢ ТОТКАН УРЫНЫ ҺӘМ РОЛЕ

***М.В. Лотфуллин***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Ш.Мәрҗәни исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*maratlv50@gmail.com*

Ана теленең этнослар белән, халык тарихы белән турыдан-туры бәйләнеше мәсьәләләре карала. Туаган телне саклауның кеше хокуклары белән бәйләнеше ассызыклана. Тел хокукларын саклау буенча игълан ителгән халыкара документларның Россиядә кабул ителгән карарларның, хокуки-норматив нигезләренә туры килүе ачыкланды. Шул ук вакытта Россия мәгариф өлкәсендәге норматив документларның, халыкара документлардан аермалы буларак, ана телендә укуны, туган телләрне өйрәнүне чикләүгә юнәлдерелгәнлеге күрсәтелә. Россия мәгариф системасында туган телләрнең тоткан урыны һәм хәле ачыклана. Россиядә халыкларны һәм аларның туган телләрен саклап калу буенча тәкъдимнәр кертелә.

**Төп төшенчәләр:** халык, этник үзаң, туган тел, кеше хокулары, тел хокулары, федераль дәүләт белем стандартлары, туган тел белем компетенциясе, туган телдә укуга шартлар тудыру буенча мониторинг

Россия халыклары өчен «туган тел» төшенчәсе, телне белү дәрәҗәсенә генә түгел, шул телдә сөйләшүче халык төшенчәсе белән дә турыдан-туры бәйләнгән, милләтнең төп күрсәткече булып тора. Гомум кабул ителгән милләт билгеләмәсендә, туган тел, этник үзаңнан кала, икенче урында тора. Бу күрсәткечләрнең туры килмәве халыклар арасында барган ассимиляция процессының үсешен чагылдыра. Конституциядә билгеләнгәнчә Россиядә күпмилләтле халык Россия суверенитеты иясе һәм бердәнбер хакимият чыганагы булып тора. 68 маддә буенча һәр халык туган телен сакларга һәм өйрәнергә хокуклы.

Россия социологиясендә халыкларны ассимиляцияләүгә юнәлдерелгән, туган телнең халык белән бәйләнешен инкарь итә торган һәм туган телне шәхес белән генә бәйли торган фикер (караш) алга сөрелә: Туган тел ул кешенең билгеле бер тел мохитендә кече яшьтән махсус өйрәтүдән башка үзләштергән үз милли теле (беренче тел) [1]. Бөтен дөньяда, шулай ук Россия конституциясендә дә, туган тел итеп кеше үзенеке дип санаган халыкның теле, аны үткән буыннар һәм аларның рухи мирасы белән бәйли

торган милли һәм этник идентификациянең нигезе булып торуа торган тел санала [2, б.7].

Халыкларның үзенчәлеген саклауда һәм кешеләрнең тыныч яшәешен тәэмин итүдә телләрнең әһәмияте бик зур. Алар тотрыклы үсешне тәэмин итү, глобаль һәм урындагы мәнфәгатьләрне гармонияләштерү юлында стратегик фактор булып торалар. ЮНЕСКОның гомуми декларациясендә билгеләнеп кителгәнчә, мәдәни күп төрлелек телләрнең күп төрлелеге белән бәйләнгән. Шуңа күрә үзеңнең телеңне куллануга, шул исәптән мәгарифтә дә, берүк вакытта гомумдәүләт телен һәм халыкара телләрне үзләштерүгә, доминант тел ияләрен башка милли телләрне, халыкара телләрне өйрәнүгә юнәлдерелгән тел политикасын үстерү, алга этәрү бик мөһим. Глобализация заманында барлык телләргә дөньяда үз урынын табарга аңлы рәвештә үстерелеп килә торган күптеллелек кенә мөмкинлек бирә ала.

2009 елдан бирле укытуның федерация дәүләт белем стандартларын (ФДБС) эшләү бара. Стандартлар белем үзләштерүгә, уку-укыту шартларына, тәрбия нәтиҗәләренә таләпләр булып кабул ителә. Элек эшләнгән стандартлардан аермалы буларак, яңа стандартлар Европага ияреп, һәр белем циклы буенча компетенцияләр формасында бирелә. Бу компетенцияләр «Европа Советы һәм Парламенты тәкъдимнәрендә» (2006 ел, 18 декабрь, № 2006/692/ЕС) аңлатыла. Аларны 2 группага бүлеп була: гомуми (универсаль, төп, профессиядән тыш) һәм махсус (профессиональ). Гомуми группага 8 төп компетенция керә, шулар арасында беренче урында туган телне белү компетенциясе. Еврокомиссия тәкъдимнәре буенча Болон процессына катнашучы илләрдә балалар бакчасыннан алып, югары белем һәм аннан соң укуда да туган телдә аралаша алу иң мөһим һәм беренче компетенция булып санала. Россиянең Болон процессына катнашуына карамастан, яңа стандартта туган тел белү компетенциясе дәүләт теле буларак рус телен белү компетенциясенә алыштырылган [3].

Әлбәттә, Россия Конституциясе һәм халыкара документлар нигезендә туган телне белү төп компетенция булырга тиеш. Туган телен белмәгән кешеләр белемле, укымышлы дип саналмаска һәм аларга белем турында документ бирелмәскә тиеш. «Мәгариф системасы халык тормышының яшәү рәвешен формалаштыра, яңа буыннарга милләтнең кыйммәтләрен тапшыра» (Россия Президенты Д.А.Медведевның Федерация Собраниесенә посланиесе (2008 ел, 5 ноябрь)).

Белем бирүнең ФДБС кысаларында эшләнгән үрнәк программаларның туган тел һәм әдәбиятын укытуда ирешелгән дәрәҗәдә булулары зарур, алар туган тел һәм әдәбиятны Россиядә барлык укучыларга укытуны тәэмин итәргә тиеш. Россия халыкларының телләрен саклап калуның зарури шарты булып ФДБС ка туган телләрне 9, 11 классларда дәүләт йомгаклау аттестациясе белән төп компетенция итеп кертү тора. Мәҗбури белем бирү шартларында туган телдә уку һәм аны өйрәнү үзиреклелек принцибына корылу чынбарлыкта халыкларның үз телендә массакүләм

рәвештә укый-яза белмәвенә китерә. Бу исә халыкларның үз телләрен һәм мәдәниятләрен югалтуына алып бара. Безнең исәпләүләр буенча Россия регионнары мәктәпләрендә 7% кына татар баласы туган телен өйрәнә. Шул ук вакытта Россия конституциясе гражданнар хокукларын социаль, раса, милли, тел һәм дин билгеләренә карап чикләүнең бөтен формаларын тыя (19 нчы маддә). Шулай итеп, Россия конституциясе, туган тел куллану хокукы белән беррәттән һәркемнең белем алырга хокукын игълан итеп барлык халыкларга туган телләрен сакларга гарантия бирә. 16 нчы матдә буенча халыкара хокукларның гомүм танылган принциплары, нормалары һәм халыкара килешүләр Россия хокуки системасының бер өлеше булып торалар. Әгәр Россиянең халыкара килешүе Россия законында каралган кагыйдәләргә туры килмәсә, халыкара килешүдәге кагыйдәләр кулланыла.

Тел хокукларының мөһим нигезе булып кеше хокуклары буенча кабул ителгән халыкара доументлар тора: БМО (Берләшкән милләтләр оешмасы)ның кеше хокуклары буенча гомуми декларациясе (1948), ЕКХО (Европа куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек оешмасы)нда катнашучы илләр (шул исәптән Россия дә) консесусы белән кабул ителгән Кешелек үлчәнеше Конференциясенең Копенгагендагы очрашуы документы (1990), Милләт яки этник, дин, тел азчылыкларын тәшкил иткән кешеләр хокуклары буенча БМО декларациясе (1992), 1996 елда Нью-Йоркта төзелгән Экономик, социаль, мәдәни хокуклар буенча халыкара Пакт (ICESCR), шулай ук Гражданлык һәм сәяси хокуклар буенча халыкара Пакт (ICCPR). Мәгарифкә караган халыкара стандартларга да шул ук кеше хокуклары буенча кабул ителгән халыкара документларда нигез салынган [4]. Копенгаген документының 34 нче параграфында: «Катнашучы илләр милли азчылыкларга дәүләтнең рәсми телен яки телләрен өйрәнү зарур булуга карамастан, туган телләрен өйрәнүгә яки туган телдә укуга мөмкинлек булдыруны гарантияләү буенча көч куячаклар...» дип белдерелә. Туган телне өйрәнүгә яки туган телдә укырга шартлар тудыру шулай ук БМО ның 1992 нче елдагы Декларциясендә дә һәм кайбер икеяклы килешүләрдә дә каралган. 1996 нчы елгы Гаага тәкъдимнәрендә азчылык телләрдә башлангыч, урта, урта махсус һәм югары белем бирү зарурлыгы күрсәтелгән.

Мәгариф системасында тел хокуклары азчылыкны тәшкил халык телләренә өйрәтүне; милли азчылык әгзаларын һәм башка ул телне өйрәнергә теләүчеләрне; һәм милли азчылыкларны туган телдә укытуны үз эченә ала. ЕКХОның милли азчылыклар буенча Баш Комиссары фикере буенча дәүләтләрнең бу ике мөмкинлекне дә бирергә хәзерлеге азчылыкларның хокукларын яклау өчен бик мөһим.

Беренчедән, төп кеше хокукын «үз телен куллануда» (Гражданлык һәм сәяси хокуклар буенча халыкара Пакт (ICCPR), 27 нче маддә) милли азчылыктан булган кешеләргә тормышка ашыру аларның туган телләрен белү мөмкинлегеннән тора. Гаага тәкъдимнәрендә әйтелгәнчә, милли азчылыктан булган кешеләрнең үзбилгеләү хокукы алар белем алу барышында ана телләреннән дә белем алган очракта гына тулысынча тормыш-

ка ашырыла ала. Сөйләм телен белүне гаиләдә тәэмин итеп булса да, язма һәм әдәби телне белү – укыту оешмаларының актив эшчәнлеген таләп итә. Аның өстенә өлкән кешеләр махсус программаларга таянып укырга теләргә мөмкин.

Икенчедән, азчылык теленә азчылыктан булмаган кешеләрне дә өйрәтү азчылык белән күпчелек арасында аңлашуга бигеле бер өлеш кертергә мөмкин. Күптән түгел Европа Советы мәдәни аралашу, аңлашу һәм толерантлык чарасы буларак бердән күбрәк тел белүнең әһәмиятен таныды.

Өченчедән, тел дәресләре тел өйрәнүченең һәм шәхеснең үзбилгеләвен тәэмин итүче элемент булып торса да, уку процессының зуррак өлеше туган телдә укытылган очракта гына тел тулысынча үзләштерелергә мөмкин.

Дүртенчедән, тикшерүләр күрсәткәнчә, үз телен өйдә өйрәнүче һәм әлегә күпчелек телен яки рәсми телне өйрәнмәгән милли азчылык кешеләренә билгеле бер күләмдә туган телдә уку белем күтәрергә ярдәм итә.

Югарыда күрсәтелгән мәгариф өлкәсендәге тел хокукларын тәэмин итүче чаралар Европа Советының 1992 елның 22 нче июнендә кабул ителгән регион телләре һәм азчылык телләре буеча Европа Хартиясендә каралган. 1992 елның гыйнварендә Россия Европа Советына кабул ителә һәм Европа Советы кабул иткән бөтен документларны үтәү йөкләмәсен үз өстенә ала. Россия конституциясе бу йөкләмәләрне тулысынча үтәргә мөмкинлек бирә. Шуңа да карамастан, Россиянең «Мәгариф турында» законы туган телдә белем алуны төп мәктәп (1–9 класслар) белән чикли. Туган телләрне укытуга шартлар рәсми дәүләт (рус) телен укытуга тудырылган шартлардан күпкә начаррак булулары белән кискен аерылалар. Ул гына да түгел, Россия кануннарында каралган Россия составындагы Республикаларның дәүләт телләрен укыту Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы раслаган гомуми белемнең үрнәк программаларында урын тапмаган. Россия «Мәгариф турында» законының 14 нче маддәсендә каралган Россия республикаларының дәүләт телләрен, туган телләр белән беррәттән, төп укыту программасының мәҗбүри өлешендә укыту хокуки-норматив актлар белән беркетеп куелырга тиеш. Шулай ук, Россия мәгариф һәм фән министрлыгының 28.11.2008 елгы 362 номерлы приказы белән расланган бердәм дәүләт имтханнарын (БДИ) үткәрү турында нигезләмә (алдагы текстта – Нигезләмә) туган телдә уку мөмкинлекләрен чикли. Нигезләмәнең 5 нче пункты буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе рус телендә генә уздырыла. Шул ук вакытта, Россия «Мәгариф турында» законының 70.1 маддәсе нигезендә БДИ нәтиҗәләре югары уку йортларына керү имтиханнары нәтиҗәләре дип таныла. Димәк, БДИ ны рус телендә генә уздыру туган телдә белем алу һәм югары белем алу хокукын чикли, төп кешелек ирекләрен һәм хокукларын тел һәм милләт билгеләре буенча дискриминацияли.

Хәзерге вакытта халыкларның конституциядә каралган туган телләрен саклау буенча ихтыяҗларын кайсыдыр күләмдә үти торган регионнардагы мәгариф идарәсе органнарының укыту процессын оештыру, белем эчтәлеген билгеләү, укытучылар хәзерләү буенча вәкаләтләре юкка чыгарылган. Россия мәгариф һәм фән министрлыгы да бу вәкаләтләрне үзенә алмый. Ул хәтта регионнарда туган телләрдә укуга һәм туган телләрне өйрәнүгә шартлар тудыруга мониторинг та уздырмый. Мәсәлән, Россия мәктәпләрендә күпме бала укуы да билгеле түгел. Татар халкының 75% яшәгән Россия регионнарында татар теле укытучылары хәзерләү туктатылган, хәтта балалар бакчасына тәрбиячеләр дә хәзерләнми. Калган халыкларның хәле тагын да начарырак.

Шулай итеп, Россиядә этносларны, халыкларны, аларның телләрен һәм мәдәниятен саклап калу өчен түбәндәге оештыру чараларын күрергә кирәк.

1. «Мәгариф турында»гы Федерация законында:

– гражданнарның конституциядә каралган хокукын – туган телдә урта һәм югары белем алуны (дәүләт йомгаклау аттестациясе белән берлектә) законлаштырырга,

– Россия субъектларында туган телдә белем бирү һәм туган телне укыту буенча үрнәк укыту программалары төзү һәм раслау вәкаләтләрен тәэмин итә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Дәүләт һәм муниципалитет структураларында туган телдә укуны, тәрбияне һәм туган тел өйрәнүне тәэмин итүче штат берәмлекләре булдырырга.

3. Туган телдә уку-укыту методик әсбапларны, дәреслекләрне нәшер итү, рецензияләү буенча Бөтенроссия структурасы төзергә.

4. Федерация дәүләт белем стандартларына төп компетенция итеп туган телне белүне күрсәтергә һәм 9, 11 классларда туган тел һәм әдәбияттан дәүләт йомгаклау имтиханнары кертергә.

5. Бөтенроссия күләмендә:

– туган телдә эшли торган балалар бакчасы, урта гомуми белем һәм өстәмә белем бирә торган учреждениеләрнең нигезләмәләрен төзергә,

– туган телдә эшли торган мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре өчен вазифа инструкцияләр расларга.

6. Россия Мәгариф һәм фән министрлыгында туган телләрдә укуга, туган телләрне өйрәнүгә шартлар тудыруга мониторинг, дәреслекләр бастыруны оештыру, милли кадрлар хәзерләү вәкаләтләре булган милли мәгариф структура яңадан торгызырга.

7. Урта гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларына дәүләт йомгаклау аттестациясен рус телендә генә уздыру нигезләмәсен гамәлдән чыгарырга.

Хәзерге шартларда Россия халыкларын саклап калу өчен мәгарифнең эчтәлеге поликультуралыга әйләнергә, ә мәгариф системасы табигыйлык

юнәлеше принципларында төзелергә тиеш. Милли мәгариф оешмалары формасы ягыннан заманча модерн, эчтәлеге ягыннан милли булырга тиеш.

ӘДӘБИЯТ


1. Беликов В.И., Крысин Л.П. Социолингвистика. 2-е изд., испр. М.: Аспект Пресс, 1996. 207 с.

2. Беларусская мова. Прафесійная лексіка: дапам / аўт.-склад. В.В. Маршэўская, І.В. Піваварчык, А.С. Садоўская. Гродна: ГрДУ, 2006. 84 с.

3. Лотфуллин М.В. Современные проблемы национального образования // Современные проблемы науки и образования. 2014. №6. URL: http// www.science-education.ru/pdf/2014/6/333.pdf (дата обращения: 25.11.2016).

4. Языковые права этнических меньшинств в сфере образования. Сб. материалов / авт. пер. и сост. Г.В. Хрусталев. М., 1994. С 20–35.


**Автор турында белешмә:** Лотфуллин Марат Вазыйх улы – физика-математика фәннәре кандидаты, өлкән фәнни хезмәткәр, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге, ТР ФА Ш.Мәрҗәни исемендәге Тарих институты (420014, Кремль, 5нче подъезд, Казан, Татарстан Республикасы, Россия); maratlv50@gmail.com

## РОЛЬ И МЕСТО РОДНЫХ ЯЗЫКОВ В СИСТЕМЕ ОБРАЗОВАНИЯ РОССИИ

***М.В. Лотфуллин***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*maratlv50@gmail.com*

Исследуются взаимоотношения родных языков и этносов. Показана непосредственная связь народов с родными языками. Выявлено взаимовлияние обеспечения прав человека и сохранения родных языков. Проводится анализ международных документов по обеспечению языковых прав, и исследуется их соответствие нормативно-правовым основам России в этой области. Нормативные документы России в области образования, в отличие от международных документов, направлены на ограничение условий для обучения на родном языке и изучения родных языков. Выявляется состояние родных языков и их место в системе образования России. Вносятся предложения по сохранению народов России и их языков.

**Ключевые слова:** народ, этническое самосознание, родной язык, языковые права, федеральные образовательные стандарты, образовательные компетенции по родным языкам, мониторинг создания условий для обучения на родных языках

**Сведения об авторе:** Лотфуллин Марат Вазыхович – кандидат физико-математических наук, старший научный сотрудник, Центр истории и теории национального образования, Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ (420014, Кремль, подъезд 5, Казань, Российская Федерация); maratlv50@gmail.com

## THE ROLE AND PLACE OF MOTHER TONGUES IN THE RUSSIAN EDUCATION SYSTEM

***M.V. Lotfullin***

*Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*maratlv50@gmail.com*

This article investigates the relationships between native languages and ethnic groups. It shows that there is a direct relationship between a nation and its native language. The interrelationship between promotion of human rights and the preservation of native languages is revealed. International documents concerning provisions for language rights are analyzed and Russia's compliance with the international regulatory framework in this area is investigated. Normative Russian education documents, in contrast to the international documents, aim to restrict the conditions in which learning in the mother tongue and studying native languages can take place. The state of native languages and their place in the Russian system of education is shown. Proposals are made for the preservation of the peoples of Russia and their languages.

**Keywords:** educational competence in native languages, ethnic consciousness, federal educational standards, language rights, monitoring the creation of conditions for education in the native languages, mother tongue, people

REFERENCES

1. Belikov V.I. Krisin L.P. *Sotsiolingvistika* [Sociolinguistics]. 2nd edition, corrected. Moscow, Aspekt Press Publ., 1996. 207 p. (In Russian)

2. *Belarusskaja mova. Prafesijnaja leksika: dapam* [The Belorussian Language. Professional Lexis: Manual]. Ed. by V.V. Marsheўskaya, I.V. Pivavarchyk, A.S. Sadoўskaya. Grodna, GrDU Publ., 2006. 84 p. (In Belorussian)

3. Lotfullin M.V. Sovremennie problemi natsionalnogo obrazovanija [Contemporary Problems of National Education]. *Sovremennie problemi nauki i obrazovanija – Contemporary problems of science and education,* 2014, no. 6. Available at: http//www.science-education.ru/pdf/2014/6/333.pdf (accessed 26.11.2016). (In Russian)

4. *Jazikovie prava etnicheskix menshinstv v sfere obrazovanija. Sb. materialov* [Language Rights of Ethnic Minorities in the Spheres of Education. Collection of Materials]. Trans. G.V. Khrustalev, Moscow, 1994. pp.20–35. (In Russian)

**About the author:** Marat V. Lotfullin is a Candidate of Science (Physics and Mathematics), Senior Research Fellow, the Center of History and Theory of National Education, Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (Entrance 5, Kremlin, Kazan 420014, Russian Federation); maratlv50@gmail.com